Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 10 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. «90% күләмендә ташлама билгеләнгән I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләр, ялгыз яшәүче 80 яшьтән узган өлкән кешеләрдән, торып укучы студентлардан, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны, контракт буенча хезмәт итүче һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2024 нче елда үзарасалымны 600 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Бөек Ватан сугышынын ветераннары өчен һәйкәл ясау;
- "Газинур аланлыгы» на капка кую;
- юлларны ремонтлау;
- территорияне чистарту,

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Салавыч авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarctan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.К.Латипов